**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**КАРАР**

**17.06.2020**

**КАРАР**

**№6**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан 2015 елның 21 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль законы, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Аквакультура (балыкчылык) турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 502-ФЗ номерлы Федераль законы, Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 2015 елның 21 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Имән авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.А. Исламова

Исполнительный комитет Старо-Имянского сельского поселения
Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитеты
ОГРН 1061687003080
ИНН 1636005599

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Башкарма комитетының
17.06.2020 елның 6 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр

1) 39.6 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 29.1 пункт өстәргә:

«29.1. дәүләт яки муниципаль милектә булган балыкчылык участогыннан (алга таба – балыкчылык участогыннан файдалану шартнамәсе) файдалану шартнамәсе нигезендә товар аквакультурасын (товар балыкчылыгы) гамәлгә ашыручы затка әлеге максатлар өчен җир кишәрлеге бирү;»;

2) 30 кушымтаның 1.5 пунктының 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект»;

3) 23 кушымтаның 2.9 пунктының 3 пунктчасында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 2 кушымтаның 1 кушымтасының 2.5 пунктының 7 пунктчасындагы 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәт тарафыннан әзерләнгән мондый ширкәт әгъзаларының реестры, әгәр җир кишәрлеген алдан килештерү яисә мондый ширкәткә җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү турында гариза бирелгән булса.»;

5) 4-7 нче кушымталарның ,13-16 нчы кушымталарның, 28 нче кушымтаның 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2,9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге, әлеге ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир участогы бакча яки яшелчә бакчасы булса) яисә җир кишәрлекләре милекчеләренең үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеге бүлеге нәтиҗәсендә барлыкка килсә (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);

6) 6 нчы кушымтаның 1 нче кушымтасындагы 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлекләре, мондый ширкәт әгъзаларына гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләреннән тыш;»;

7) 5 нче кушымтаның 1 нче кушымтасындагы 2 пунктның 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11) бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләренә биш елдан да артмаган срокка;»;

8) 7 нче кушымтаның 1 нче кушымтасының 3 пунктындагы 2 пунктчасында "яисә дача хуҗалыгы" сүзләрен төшереп калдырырга.

9) 7 нче кушымтаның 1 нче кушымтасындагы 2 пунктның 7 һәм 8 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7)коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән бакчачылык яки яшелчәчелек җир кишәрлекләре, мондый ширкәт әгъзаларына гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләреннән тыш;»;

8) гражданнар тарафыннан бакчачылык яисә үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге әйләнешендә чикләнгән җир кишәрлеге, мондый территория чикләрендә бакча яисә яшелчә кишәрлекләренең хокук ияләре булган гражданнарга арендатор ягында күпсанлы затлар булган (күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү зарурлыгы мондый территория чикләрендә гомуми файдалану мөлкәте белән идарә итүче бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышында каралган очракта);»;

10) 4 нче кушымтаның 1 нче кушымтасының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 3)территорияне межалау проекты нигезендә төзелгән һәм гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булып торучы җир кишәрлеге,мондый территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләре булган затларга әлеге кишәрлекләрнең мәйданнарына пропорциональ рәвештә гомуми өлешле милеккә;»;

11) 1.5 пунктның 10 абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре» сүзләрен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләре» сүзләренә алмаштырырга;

12) 3.5.2 пунктта «мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар» сүзләрен «карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга»;

13) 3.5.1 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылганчы аларны уздыру турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларын үткәрү вакыты муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да артмаска тиеш»;

14) 7 нче кушымтаның 1 нче кушымтасындагы 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3_1 пункт өстәргә:
«3_1) акчалары күпфатирлы йортларны төзү һәм аларның хокуклары өчен җәлеп ителгән, алар зыян күргән гражданнар реестрына "Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзүдә һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә, Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты боерыгы нигезендә өч һәм аннан да күбрәк блоклы төзелеш йортлары һәм (яисә) блокланган төзелеш йортлары төзү (булдыру) өчен кертелгән тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын төзүне тәгәлләү һәм төзүченең гражданнар алдында бурычларын үтәүне үз өстенә алган юридик затларга җир кишәрлеге;»;

15) 11 нче кушымтаның 2.9 пунктының 4 пунктчасына « әгәр мондый бүлү әлеге Кодексның 27 статьясындагы 5 пунктының 7 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләре белән территорияне межалау проекты нигезендә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.